*Буа районы “Кояшкай” балалар бакчасы гәҗите*

**№4** *Декабрь, 2020 ел*




Бүгенге санда

1. Яңа ел килә...
2. “Яңа ел могҗизасы”акциясе
3. “Фликер- игелекле дус”
4. “Арт-платформа”



## Хөрмәтле хезмәттәшләр!

***Сезне чын күңелдән якынлашып килүче Яңа 2021 ел белән котлыйбыз!***

***Тагын бер елны тарихта калдырып алга атлыйбыз, үткәннәргә нәтиҗәләр ясыйбыз.***

***Киләчәктә куйган максатларга тугры калып, яңадан-яңа уңышларга ирешергә язсын, күңелләребездә ышаныч уты сүнмәсен.Яңа ел һәр йортка иминлек, гаиләләргә тынычлык, муллык һәм бәхет-шатлыклар китерсен иде!***

***Сезнең һәрберегезгә рух ныклыгы, күңел көрлеге һәм сәламәтлек телибез. Ил-көнебез тыныч, барыр юлларыбыз киң, туар таңнарыбыз имин булсын. 2021 ел яңа бәхетләр алып***

*Ап-ак карларга уралып*
*Син киләсен Яңа ел!*
*Ак карлардай ак бәхетле,*
*Булсын безнең яңа юл.*
*Хуш киләсең, Яңа ел!*
*Табыныбыз мул булсын,*
*Якыннарым, дус-ишьләрем,*
*Табын түрендә торсын!*

*Яңа ел барыбызга*
*Китерсен бәхет, шатлык.*
*Сәламәтлек юлдаш булсын!*
*Кирәкми башка затлык.*
*Тынычлык булсын илдә,*
*Елмайсын йөзләр гел дә!*
*Күк йөзендә кояш безгә,*
*Нурларын сипсен гелдә!*

*Эшләребез уң булсын,*
*Тик шатлыклыминутлардан*
*Безнең гомерләр торсын!*
*Яңа ел котлы булсын!*

*Иң изге теләкләр белән балалар бакчасы мөдире Э.З.Абузарова*

## Уен-викторина “Юл йөрү кагыйдәләрен белүчеләр "





Юл-транспорт имгәнүләрен кисәтү, юл хәрәкәте кагыйдәләрен кабатлау һәм ныгыту максатыннан 4 нче декабрь көнне "Кояшкай" балалар бакчасында "Юл хәрәкәте кагыйдәләрен белүчеләр" дип исемләнгән танып-белү уены-викторина үтте. Уенда өлкән төркемнәрнең ике командасы катнашты: "Зебра"һәм "Светофор".

Балалар барлык тәкъдим ителгән биремнәрне мавыгып башкардылар. Чара ахырында чакырылган кунаклар: "Юл хәрәкәте иминлеге "ДБУнең Казан шәһәрендәге ТУ профилактикалау бүлеге начальнигы Мурзакова С.М. һәм юл хәрәкәте иминлеге пропагандасы буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече Санатуллина Э.И. катнашучыларга бүләкләр тапшырдылар.

## “Яңа ел могҗизасы" акциясе





Яңа ел алдыннан "Кояшкай" балалар бакчасы волонтерлары ата-аналары белән бергә "Яңа ел могҗизасы"акциясендә актив катнаштылар. Алар үзәк район хастаханәсенең балалар бүлегендә дәваланучы балалар, ковид- бүлегендә көн - төн эшләүче табиблар өчен яңа ел бүләкләре әзерләделәр. Чыршы уенчыклары, мишура, китап – раскраскалар бәйрәм кәефе булдырырга һәм яңа елның якынаюын тоярга ярдәм итәр дип ышанабыз. Якынлашып килүче Яңа ел белән!

## Котлыйбыз!!!



Бакчабызның зурлар төркеме балалары"Фликер –игелекле дус" дигән видеоролик конкурсында катнаштылар.Лаеклы 2 урын белән котлыйбыз.





Бакчабызның зурлар төркемендә тәрбияләнүче Ибраһимова Камилла, Нәфиева Айзилә, Гәрәева Самина, Шәрифҗанова Исламия "Арт - платформа" халыкара иҗади талантлар конкурсында катнаштылар һәм "Янгаравык тавышлар"вокаль ансамбле номинациясендә 2 дәрәҗә лауреат булдылар.

# Балалар белән ятларга шигырьләр

### Кар бабай

Тәгәрәтеп ак карны,
Ясадык кар бабайны.
Куйдык кишердән борын,
Ясадык ике кулын.
Күзләре – кара күмер.
Дидек: “Син урам себер!”
Зур себерке тоттырдык,
Көлешеп карап тордык.

### Буранда

Тышта ыжгырып
Җил-буран дулый,
Күзеңне ачып
Карап та булмый.
Шундый буранда
Нәни энесен
Бакчага илтә
Апасы Гөлсем.



– Курыкма, энем,
Җилдән-бураннан,
Батырлык яхшы
Куркак булганнан.
Ә.Бикчәнтәева

### Кар яуганда

Энем минем кар яуганда
Чыга чана шуарга,
Артка карый – эз юк була;
Хәйран кала шуңарга:
– Апа, апа, кая качкан
Минем чана шуган юл?
– Мамык карлар явып узгач,
Кар астында калган ул.
М.Фәйзуллина

# Табышмакларга җавап тап

Кышын тауда шуалар,
җәен җыеп куялар.
Нәрсә ул?



Йолдыз, йолдыз вак кына,
Яфраклары ак кына.
Өс киемеңә куна,
Тәнгә тисә су була.





Ике агай тездән,
Калышмыйлар бездән.



Килә бары кыш җиткәч,
Иске ел үтеп киткәч.
Үзе белән һәрвакыт
Яңа ел алып килә.
Бүләк тулы капчыгын
Иңенә салып килә.

Шома табанлы чана
Атсыз да алга чаба -
Җитез булса аяклар,
Кулда була таяклар.
Бар бер чана
Утырасы юк,
Бассаң-үзе чаба.
Нәрсә ул?



Җәй дә яшел
чапанлы,
Кыш та яшел
чапанлы.







## Кар бабай ясау

Урамда ап-ак ... ява.
Малайлар кардан ... ясыйлар. Алар ... тәгәрәтәләр.
Кар бабайның борынына ..., күзләренә ... куялар.
Кар бабай бик матур була.
Үз эшләренә карап ... бик шатланалар.
(Күп ноктalar урынына тиешле сүзләрне сайлап куй:
Кар, шар, кар бабай, кишер, күмер, балалар)



# Кроссвордны чиш!

Рәсемнәрдә сурәтләнгән мультфильм персонажларының исемнәрен башваткычтан табыгыз. Кызыл төстәге хәрефләрне буш шакмакларга дөрес итеп язсагыз, мультипликация белән бәйле профессия исеме килеп чыгар.





| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Е | Б | У | Е | Н | О | Л | У | Н | К | В | У |
| Ч | А | Р | Г | А | П | Ь | Ф | Т | И | И | Д |
| Ш | Ш | К | А | Е | О | Д | Ю | Ш | О | С | Я |
| А | П | Л | Я | Л | П | У | Н | А | Л | А | Ш |
| Э | О | К | К | Н | И | Х | Р | А | А | Ш | Д |
| Н | Д | К | А | Н | И | Й | А | Ш | М | Е | Ж |
| А | И | Ш | В | И | Ц | К | Б | И | Р | Р | И |
| Н | Т | О | И | Ф | А | О | П | А | У | Г | Л |
| К | А | О | Н | Б | Е | Л | Ш | Т | А | М | Ш |
| Л | Р | Б | У | Н | К | М | Е | Ы | О | М | О |
| С | О | Н | Л | Т | И | Ә | М | Ч | Т | К | Р |





«Нурчыклар» гәҗитен гамәлгә куючы: Татарстан Республикасы Буа шәһәренең катнаш төрдәге “Кояшкай” балалар бакчасы” муниципаль бюджет учреждениесе

Редколлегия әгъзалары: Гиниятуллина Д.Р.

Безнең адрес: 422430, Буа шәһәре, Арефьева урамы, 13 йорт

Тел. (843)743-13-09
E-mail: colnush-bua@mail.ru